ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

16 февраль 2024 ел

**КАРАР**

№ 1007

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә экологик агартуны гамәлгә ашыру һәм экологик культура формалаштыру турында нигезләмәне раслау хакында

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә экологик агартуны гамәлгә ашыру һәм экологик культура формалаштыру турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 16 февралендәге
1007 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
экологик агартуны гамәлгә ашыру һәм экологик культура формалаштыру турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 11 пункты нигезендә эшләнде һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә экологик агартуны гамәлгә ашыруның, экологик культура формалаштыру өчен шартлар тудыруның хокукый һәм оештыру нигезләрен билгели.

2 бүлек. Әлеге нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр

2. Әлеге нигезләмә максатлары өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

1) әйләнә-тирә мохит торышы турында мәгълүмат (экологик мәгълүмат) – аларның әйләнә-тирә мохит турында күзаллау формасына бәйсез рәвештә, шул исәптән әйләнә-тирә мохитнең ретроспектив, агымдагы һәм фаразлана торган торышы, аның пычрануы, анда бара торган процесслар һәм күренешләр турында, шулай ук гамәлгә ашырыла һәм планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысы турында, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә үткәрелә һәм планлаштырыла торган чаралар турында мәгълүматлар (хәбәрләр, мәгълүматлар);

2) экологик культура – социаль мөнәсәбәтләр, әхлакый кыйммәтләр, кеше һәм җәмгыятьнең әйләнә-тирә мохит белән үзара эшчәнлеге нормалары һәм ысуллары системасын үз эченә алган дөньякүләм һәм милли мәдәниятнең аерылгысыз өлеше;

3) экологик агарту – экологик культура формалаштыру, табигатькә карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү һәм табигатьтән рациональ файдалану максатларында экологик иминлек турында экологик белем, әйләнә-тирә мохит торышы турында һәм табигать ресурсларыннан файдалану турында мәгълүмат тарату;

4) экологик туризм – табигать мохитенә зыян китерми торган ял оештыру һәм табигый-фәнни яки гамәли белем һәм тәҗрибә алу максаты булган, табигатькә юнәлдерелгән туристик эшчәнлек.

3 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
экологик агартуның һәм экологик культура формалаштыруның
төп максатлары һәм бурычлары

3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә экологик агартуның һәм экологик культура формалаштыруның төп максатлары булып тора:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә табигатькә карата сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру һәм экологик культураны арттыру;

2) уңай әйләнә-тирә мохитне, биологик төрлелекне һәм табигать ресурсларын саклап калу.

4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә экологик агартуның һәм экологик культура формалаштыруның төп бурычлары:

1) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек өлкәсендә халыкны мәгълүмати тәэмин итү;

2) гражданнарны, иҗтимагый һәм башка оешмаларны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә экологик әһәмияткә ия эшчәнлекне тормышка ашыруда катнашуга җәлеп итү;

3) балаларны, яшьләрне һәм башка социаль төркемнәрне Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә әйләнә-тирә мохитне саклау, табигатьтән рациональ файдалану өлкәсендә экологик юнәлешле эшчәнлеккә җәлеп итү;

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә экологик туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;

5) калдыклар белән эш итүгә, шул исәптән каты коммуналь калдыкларны аерым җыюга җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру.

## 4 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә экологик агарту һәм экологик культура формалаштыруның төп принциплары

5. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә экологик агартуның һәм экологик культура формалаштыруның төп принциплары булып тора:

1) экологик белем бирүнең һәм агартуның системалылыгы, комплекслылыгы һәм өзлексез булуы;

2) мәгариф системасында экологик белемнәрнең өстенлеге;

3) экологик белем һәм тәрбия бирүнең гражданнар тарафыннан табигать мохитен саклау һәм торгызу, аның ресурсларыннан сак файдалану өчен шәхси җаваплылыкны төгәл аңлавын формалаштыруга, шулай ук үз-үзен тотуның тиешле нормаларын формалаштыруга юнәлдерелгән булуы;

4) экологик мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы;

5) экологик белем бирүнең һәм агартуның гомумилеге (халыкның барлык социаль һәм яшь төркемнәрен укытуны һәм агартуны тәэмин итү);

6) экологик белем бирү һәм агарту өлкәсендәге сәясәтне эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда хәбәрдарлык;

7) экологик белем бирү һәм агарту системасын үстерү буенча конкрет эшчәнлекне стимуллаштыруга юнәлдерелгән булуы.

## 5 бүлек. Экологик агарту, экологик культура формалаштыру өлкәсендә гражданнарның, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның хокуклары

6. Экологик агарту һәм экологик культура формалаштыру өлкәсендә гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар түбәндәгеләргә

хокуклы:

1) экологик агарту, экологик культура формалаштыру өлкәсендә җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тормышка ашыру һәм камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

2) муниципаль программалар проектларын һәм экологик агарту буенча планнарны эшләүдә һәм, әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүне үткәргәндә, иҗтимагый фикер алышуларда катнашу юлы белән аларны тормышка ашыруда катнашырга;

3) экологик агарту буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле, дөрес булган экологик мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә сорарга һәм алырга;

4) интерактив белем бирү технологияләрен, күргәзмәләрне һәм экологик программаларны һәм укыту-агарту материалларын тәкъдир итүне тормышка ашырырга;

5) халыкның хокукый һәм экологик культурасын формалаштыру һәм арттыру максатында өмәләр оештырырга, территорияләрне төзекләндерү һәм яшелләндерү эшендә, смотрларда, конкурсларда, конференцияләрдә, семинарларда, мәгълүмати һәм башка кампанияләрдә актив катнашырга;

6) законнар нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## 6 бүлек. Халыкны экологик агарту

7. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә экологик агарту һәм экологик культура формалаштыру буенча эшчәнлекне координацияләү Башкарма комитетның мәгариф идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Экологик агарту һәм экологик культура формалаштыру җирле үзидарә органнары тарафыннан түбәндәге формаларда гамәлгә ашырыла:

1) әйләнә-тирә мохитне саклау, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, экологик иминлек өлкәсендәге законнар турында мәгълүмат бирү;

2) экологик белемнәрне пропагандалау, әйләнә-тирә мохитнең, табигать ресурсларының торышы һәм экологик иминлек турында мәгълүмат тарату;

3) экологик-агарту эшчәнлеге (форумнар, конкурслар, фестивальләр, күргәзмәләр, экология акцияләре һәм башкалар);

4) гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка формалар.

## 7 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә экологик агартуда һәм экологик культура формалаштыруда катнашу

9. Чараларны тормышка ашыруга ихтыярый нигездә табигатьне саклау, белем бирү, иҗтимагый һәм башка оешмалар җәлеп ителергә мөмкин.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева